СОВЕТ
МЕНЗЕЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНЗӘЛӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

14.12.2016 ел г. Мензелинск № 14

**Авыл җирлекләрендә халыкка күрсәтелә торган 2017 елга каты коммуналь калдыкларны (ТКО) чыгару тарифлары турында**

«Коммуналь комплекс оешмалары тарифларын җайга салу нигезләре турында» 2004 елның 30 декабрендәге №210-ФЗ Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Коммуналь комплекс оешмалары эшчәнлеге өлкәсендә тарифлар, өстәмәләр һәм чик индекслар төзү нигезләре һәм аларны җайга салу тәртибе турында» 2008 елның 14 июлендәге №520 карары, «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә коммуналь хезмәтләр күрсәткән өчен түләүнең чик (максималь) индекслары турында» Татарстан Республикасы Президентының 2016 елның 28 ноябрендәге № УП-1055 Указы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында коммуналь калдыкларны туплау нормативларын раслау турында» 2016 елның 12 декабрендәге №922 карары нигезендә

МИНЗӘЛӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ КАРАР ЧЫГАРА:

1. 2017 елның 1 гыйнварыннан 2017 елның 30 июненә кадәр авыл җирлекләре халкы өчен каты коммуналь калдыкларны чыгару буенча коммуналь хезмәтләр өчен түләү тарифларын, календарь төшенкелек белән өстәлгән салымны исәпкә алып, билгеләргә һәм гамәлгә кертергә:

**2017 елның 1 гыйнварыннан 2017 елның 30 июненә кадәр 2016 ел дәрәҗәсендә үзгәрешләрсез:**

- аена бер кешедән 37,0 сум.

**2017 елның 1 июленнән 2017 елның 31 декабренә кадәр:**

- Бер кешедән аена 38,55 сум.

2. «Авыл җирлекләренә бирелә торган 2016 елга көнкүреш калдыкларын чыгару тарифлары турында» 2016 елның 25 июлендәге №7 Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Советы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны икътисад, бюджет һәм эшкуарлык комиссиясе рәисе Р.Ш.Газиҗановка , Минзәлә шәһәре башкарма комитеты җитәкчесе И.Т.Шагалиевка, Минзәлә муниципаль районы башлыгы урынбасары К.Р. Нәҗмиевка йөкләргә.

Совет рәисе А.Ф. Сәлахов